СОВЕТ АЛАН-БЕКСЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422723, Республика Татарстан, Высокогорский район, село Алан-Бексер, ул. Центральная, 19

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк урамы, 19

Тел./факс 8(84365) 63-4-30, e-mail: Kazak.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**14 декабря 2023 г.** **№ 91**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советы Татарстан Республикасы Карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 13.12.2019 № 207 карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына (Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 06.08.2020 № 225, 19.01.2021 № 24, 19.08.2022 № 60 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. «Авыл торак пункты старостасы» 20 статьясының 2, 3 өлешләрен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Авыл торак пункты старостасы авыл җирлеге гражданнары җыены тәкъдиме буенча, составына әлеге авыл торак пункты кергән авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә. Авыл торак пункты старостасы әлеге авыл җирлеге территориясендә яшәүче һәм актив сайлау хокукына ия булган Россия Федерациясе гражданнары, яки гражданнар җыены тәкъдим иткән көнне 18 яшен тутырган һәм әлеге авыл җирлеге территориясендә урнашкан торак бинасы булган Россия Федерациясе гражданнары арасыннан билгеләнә.

3. Авыл җирлеге старостасы дәүләт вазыйфасын, дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын, муниципаль вазыйфаны алмаштыручы зат түгел, үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыручы җирлек Советы депутаты муниципаль вазыйфасыннан яки муниципаль хезмәт вазыйфасыннан тыш, хезмәт мөнәсәбәтләрендә һәм җирле үзидарә органнары белән турыдан-туры бәйле башка мөнәсәбәтләрдә тора алмый.»

1.2. 32 статьяның 10 өлешендә "Татарстан Республикасы Президенты" сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы - Рәисе» сүзләре белән алыштырырга.

1.3. 32 статья “Җирлек Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, җирлек башлыгы статусы” дигән 32 статьяны түбәндәге эчтәлектәге 15 өлеш белән тулыландырырга:

«15. Депутат, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи заты, муниципаль вазыйфаны биләүче бүтән зат Россия Федерациясендә һәм башка федераль законнарда коррупциягә каршы тору максатларында, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне, бурычларны үтәмәү күрсәтелгән затлардан бәйсез булган шартларда тикшерү тарафыннан 2008 елның 25 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында" Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә танылган очракта, «Җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне һәм бурычларны үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә”.

1.4. “Җирлек Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату” 42 статьяны түбәндәге эчтәлектәге 1.1 өлеше белән тулыландырырга:

«1.1. Җирлек Советы депутатының вәкаләтләре җирлек Советы карары белән, депутат җитди сәбәпләрсез алты ай рәттән җирлек Советының барлык утырышларында катнашмаган очракта вакытыннан алда туктатыла.»

1.5. 42 статьяның 5 өлешендә "Татарстан Республикасы Президенты" сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы - Рәисе» сүзләре белән алыштырырга.

1.6. 44 статьясындагы 1 өлешнең 2 абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы - Рәисе» сүзләре белән алыштырырга.

1.7. “Җирлек башлыгы статусы” 45 статьясян түбәндәге эчтәлектәге 6 өлеш белән тулыландырырга:

«6. Җирлек башлыгы Россия Федерациясендә һәм башка федераль законнарда коррупциягә каршы тору максатларында, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне, бурычларны үтәмәү аннан бәйсез булган шартларда тикшерү тарафыннан 2008 елның 25 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында" Федераль законның 13 статьясындагы 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә танылган очракта, «Җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне һәм бурычларны үтәмәгән өчен җаваплылыктан азат ителә.

1.8. 48 статьядагы 3 өлешнең 2 абзацында «Татарстан Республикасы Башлыгы - Рәисе» сүзләрен алыштырырга.

1.9. 48 статьяның 4 өлешендә "Татарстан Республикасы Президенты" сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы - Рәисе» сүзләре белән алыштырырга.

1.10. “Муниципаль норматив хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка чыгару) һәм үз көченә керү тәртибе” исемле 81 статьяның 8 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Бастырып чыгарганда (халыкка чыгарганда) муниципаль хокукый актның реквизитлары күрсәтелергә тиеш.

Муниципаль хокукый актларны һәм җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләрне рәсми рәвештә бастырып чыгару (халыкка җиткерү) юллары:

- муниципаль хокукый акт текстын яки муниципаль хокукый акт проектын "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ -веб-адресы буенча урнаштыру;

- муниципаль хокукый акт текстын авыл җирлеге территориясендәге авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштыру. Әлеге стендларның саны һәм урнаштыру урыннары җирлек Советы тарафыннан раслана һәм җирлек халкының муниципаль хокукый акт тексты белән тоткарлыксыз танышу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш;

- хокукый акт текстын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру».

2. Әлеге карарны законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәве узганнан соң, Биектау районы Алан-Бәксәр авылы, Үзәк урам, 19 йорт адресы буенча урнашкан авыл җирлеге башкарма комитеты банасында куелган махсус мәгълүмат стендына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгару юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясының 8 өлешенә ярашлы рәвештә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы                                        З.Р.Гарифуллина